**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Серекино торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Серекино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Мичурин авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, МХОда катнашучылардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Сережкино авылындагы юлларны кардан чистарту);
2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Сережкино авылындагы балалар мәйданчыгын койма белән тотып алу)

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 251 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 130 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 130 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Серекино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Мичурин авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, МХОда катнашучылардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Сережкино авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Сережкино авылындагы балалар мәйданчыгын койма белән тотып алу)

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин исемендәге поселок ур., Совет ур., 26 йорт – административ бина, Совет ур., 28 йорт – мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 йорт – мәдәният йорты бинасы, Үзәк ур., 15 йорт – мәктәп бинасы, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Мичурин авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Иванова